Әлеге Законның 2 статьясындагы 2, 3 һәм 5 пунктларында билгеләнгән чикләүләр әлеге Закон үз көченә кергән көнгә җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы оешмаларга һәм әлеге Закон үз көченә кергән көнгә сыраны һәм сыра эчемлекләрен, сидрны, пуарены, әче балны ваклап сатуны гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарларга карата әлеге Закон үз көченә кергән көннән соң өч ай узгач кулланыла.

**4 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» 2010 елның 22 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 11);

2) «Татарстан Республикасы территориясендә әзер продукция күләменең 15 проценттан артыграгы этил спирты булган алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 10 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10);

3) «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 20 маендагы 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 5).



**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 6 марты
№ 10-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 201. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3; № 9; 2013 № 4 (I өлеш); 2014, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен исәпкә алып, халыкны һәм территорияләрне региональ, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеген оештыру тәртибен билгеләү һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итү.»;

2) 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеге**

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеге халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә махсус вәкаләт тапшырылган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 6 марты
№ 11-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 202. Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

1 бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-Ф номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасында стратегик планлаштыруның (алга таба – стратегик планлаштыру) хокукый нигезләрен, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының стратегик планлаштыру өлкәсендә вәкаләтләрен билгели һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш максатын билгеләү, аны фаразлау, планлаштыру һәм программалаштыру барышында стратегик планлаштыруда катнашучылар арасында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2 статья. **Стратегик планлаштыруны хокукый җайга салу**

1. Стратегик планлаштыруны хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә нигезләнә һәм федераль конституциячел законнар, Федераль закон, башка федераль законнар, шулай ук Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр һәм терминнар Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

2 бүлек. **Стратегик планлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре**

3 статья. **Стратегик планлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләре**

Стратегик планлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Россия Федерациясе социаль-икътисадый үсеше өстенлекләре һәм максатлары белән килештерелгән Татарстан Республикасы социаль-икътисадый сәясәтенең өстенлекләрен, Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы максатларын һәм бурычларын билгеләү;

2) Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасында эшләнә торган стратегик планлаштыру документларының эчтәлегенә, аларны әзерләү тәртибенә, карауга һәм раслауга (хуплауга) таләпләр билгеләү;

3) Татарстан Республикасы вәкаләтләренә караган мәсьәләләр буенча стратегик планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау (хуплау);

4) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан расланган (хупланган) стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм тикшереп тору;

5) Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә эшләнә торган стратегик планлаштыру документларының килешенгән һәм нисбәтле булуын тәэмин итү;

6) Татарстан Республикасында стратегик планлаштыруны әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

7) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырыла торган мәсьәләләр буенча федераль дәрәҗәдә эшләнә торган стратегик планлаштыру документларын формалаштыруда катнашу;

8) стратегик планлаштыру өлкәсендә Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертелгән башка вәкаләтләр.

4 статья. **Стратегик планлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре**

Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары стратегик планлаштыру өлкәсендәге вәкаләтләрне Федераль закон нигезендә гамәлгә ашыралар.

3 бүлек. **Стратегик планлаштыру системасы**

5 статья. **Стратегик планлаштыруда катнашучылар**

Стратегик планлаштыруда катнашучылар:

1) Татарстан Республикасы Президенты;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

4) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары;

5) Татарстан Республикасы Хисап палатасы;



6) әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән норматив хокукый актларда каралган очракларда башка органнар һәм оешмалар.

6 статья. **Стратегик планлаштыруда катнашучыларның вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Президенты:

1) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш юнәлешләрен, максатларын, өстенлекләрен билгели һәм төгәлләштерә;

2) Татарстан Республикасы вәкаләтләре кысаларында стратегик максатларга ирешү юнәлешләрен һәм хәл ителергә тиешле мөһим мәсьәләләрне билгели;

3) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына озак сроклы чорга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен тәкъдим итә;

4) стратегик планлаштыру өлкәсендә башка карарлар кабул итә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы:

1) стратегик планлаштыру өлкәсендә законнар ярдәмендә җайга салуны гамәлгә ашыра;

2) озак сроклы чорга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслый;

3) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) стратегик планлаштыру өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итүдә катнаша, күрсәтелгән өлкәдә норматив хокукый актлар проектларын әзерләүне оештыра һәм Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә стратегик планлаштыруны методик тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

2) стратегик планлаштыруның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карамагындагы документларын әзерләү һәм корректировкалау тәртибен билгели һәм мондый документларны раслый (хуплый);

3) Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә стратегик планлаштыруны методик яктан тәэмин итү тәртибен билгели;

4) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын һәм алардагы күрсәткечләрне әзерләүнең эзлеклелеген һәм үзара бәйләнешен билгели, шулай ук стратегик планлаштыру документларын әзерләү өчен, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш өстенлекләреннән чыгып,

максатчан күрсәткечләр системасын формалаштыру тәртибен билгели;

5) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең максатларын, бурычларын һәм күрсәткечләрен билгели;

6) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларының килешенгән һәм нисбәтле булуын тәэмин итә;

7) Татарстан Республикасының түбәндәге стратегик планлаштыру документларын раслый:

а) уртача һәм озак сроклы чорга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразын;

б) озак сроклы чорга бюджет фаразын;

8) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карамагындагы мәсьәләләр буенча стратегик планлаштыру документларын мониторинглауны һәм аларны тикшереп торуны гамәлгә ашыра;

9) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыру турында хисаплар (докладлар) әзерләү тәртибен билгели;

10) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларына норматив һәм методик таләпләрне тикшереп торуны гамәлгә ашыра, моңа аларны әзерләү һәм корректировкалау эзлеклелегенә һәм тәртибенә карата таләпләр дә керә;

11) стратегик планлаштыру өлкәсендә федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары:

1) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын әзерлиләр, Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын әзерләүне һәм корректировкалауны Федераль закон, әлеге Закон һәм әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән норматив хокукый актлар нигезендә җайга салалар;

2) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглауны һәм тикшереп торуны башкаралар;

3) стратегик планлаштыру өлкәсендә Федераль закон, әлеге Закон һәм әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән норматив хокукый актлар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

5. Татарстан Республикасы Хисап палатасы:

1) «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә стратегик планлаштыру өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;



2) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә стратегик планлаштыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

### 7 статья. **Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документлары**

1. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларына түбәндәгеләр керә:

1) максатны билгеләү кысаларында әзерләнә торган стратегик планлаштыру документы – Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе;

2) фаразлау кысаларында әзерләнә торган стратегик планлаштыру документлары, аларга түбәндәгеләр керә:

а) озак сроклы чорга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразы;

б) озак сроклы чорга Татарстан Республикасы бюджеты фаразы;

в) уртача сроклы чорга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразы;

3) планлаштыру һәм программалаштыру кысаларында эшләнә торган стратегик планлаштыру документлары, аларга түбәндәгеләр керә:

а) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планы;

б) Татарстан Республикасы дәүләт программалары;

в) Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы.

2. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын әзерләү эзлеклелеге, тәртибе, аларның эчтәлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

### 8 статья. **Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын дәүләт теркәвенә алу**

Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документлары Федераль законның 12 статьясы нигезендә стратегик планлаштыру документларының федераль дәүләт реестрында мәҗбүри дәүләт теркәве узарга тиеш.

9 статья. **Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документлары проектлары буенча иҗтимагый фикер алышу**

1. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документлары проектлары, Россия Федерациясе законнары, шул исәптән дәүләт, коммерция, хезмәт урыны сере һәм закон белән саклана торган башка сер турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, иҗтимагый фикер алышуга чыгарыла.

2. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документы проекты буенча иҗтимагый фикер алышуның рәвеше, тәртибе һәм сроклары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

3. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документы проекты буенча иҗтимагый фикер алышу барышында алынган искәрмәләр һәм тәкъдимнәр Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документын әзерләү өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан каралырга тиеш.

4. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларының төп нигезләмәләре турындагы мәгълүматның ачыклыгын һәм аннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында аларның проектлары Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документын әзерләү өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының рәсми сайтында, шулай ук стратегик планлаштыруның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге һәркем файдалана алырлык мәгълүмат ресурсында урнаштырылырга тиеш.

4 бүлек. **Татарстан Республикасының максатны билгеләү кысаларында әзерләнә торган стратегик планлаштыру документлары**

10 статья. **Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе**

1. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең Россия Федерациясе социаль-икътисадый үсеше өстенлекләре һәм максатлары белән килештерелгән өстенлекләрен, максатларын һәм бурычларын билгеләү максатларында эшләнә.



2. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразы әзерләнә торган чордан артмаган вакытка алты ел саен эшләнә.

3. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенең ирешелгән максатларын бәяләү;

2) Татарстан Республикасы социаль-икътисадый сәясәтенең өстенлекләре, максатлары, бурычлары һәм юнәлешләре;

3) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше максатларына ирешү күрсәткечләре, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары;

4) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыруның көтелә торган нәтиҗәләре;

5) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс ресурсларын бәяләү;

6) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру максатларында раслана торган Татарстан Республикасы дәүләт программалары турында мәгълүмат;

7) Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә торган башка нигезләмәләр.

4. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен әзерләү һәм корректировкалау тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5 бүлек. **Татарстан Республикасының фаразлау кысаларында эшләнә торган стратегик планлаштыру документлары**

11 статья. **Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразлары системасы**

1. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешен фаразлау, Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең ирешелгән нәтиҗәләрен, шулай ук барлыкка килгән икътисадый вәзгыятьне Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең икътисад өлкәсендәге һәм социаль өлкәдәге стратегик максатлары һәм бурычлары нигезендә үзгәртү перспективаларын исәпкә алып, озак һәм уртача сроклы перспективага гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасының озак сроклы чорга социаль-икътисадый үсеш фаразы, Россия Федерациясенең фәнни-технологик үсеш фаразын һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тапшыра торган белешмәләрне исәпкә алып, Россия Федерациясенең озак сроклы чорга социаль-икътисадый үсеш фаразы нигезендә һәр алты ел саен унике һәм аннан күбрәк елларга әзерләнә.

3. Татарстан Республикасының уртача сроклы чорга социаль-икътисадый үсеш фаразы, Татарстан Республикасының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен исәпкә алып, уртача сроклы чорга Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеш фаразы, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе нигезендә ел саен әзерләнә.

4. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана (хуплана).

5. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразларын әзерләү һәм корректировкалау тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

12 статья. **Озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразы**

Озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразы Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә әзерләнә.

6 бүлек. **Татарстан Республикасының планлаштыру һәм программалаштыру кысаларында әзерләнә торган стратегик планлаштыру документлары**

13 статья. **Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планы**

1. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планы, Россия Федерациясе Хөкүмәте эшчәнлегенең төп юнәлешләрен исәпкә алып, стратегияне башкару чорына Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе нигезләмәләренә таянып әзерләнә.

2. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.



3. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын корректировкалау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планына түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыруның, бюджет планлаштыруның билгеләнгән дәвамлылыгын исәпкә алып, бүленгән этаплары: өч ел (Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыруның беренче этабы һәм бюджет планлаштыруның агымдагы чоры өчен) һәм өч – алты ел (алдагы этаплар һәм чорлар өчен);

2) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыруның һәр этабы өчен өстенлеккә ия Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең максатлары һәм бурычлары;

3) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру күрсәткечләре һәм аларның стратегияне гамәлгә ашыруның һәр этабына билгеләнгән күрсәткечләре;

4) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыруның һәр этабында Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең стратегиядә күрсәтелгән озак сроклы максатларына ирешүне тәэмин итүче чаралар комплексы һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеге;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән башка нигезләмәләр.

14 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт программалары**

1. Татарстан Республикасы дәүләт программалары, Россия Федерациясенең стратегик планлаштыруның тармак документларын һәм Идел буе федераль округының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен исәпкә алып, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясендә билгеләнгән социаль-икътисадый үсеш өстенлекләре нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән чорга әзерләнә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеге, аларны әзерләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

3. Федераль дәрәҗәдә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы эшләргә кагылышлы максатларга ирешүгә юнәлдерелгән Россия Федерациясе дәүләт программасы расланган һәм гамәлгә ашырылган очракта, шундый ук Татарстан Республикасы дәүләт программасы әзерләнергә мөмкин.

4. Татарстан Республикасы дәүләт программалары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә раслана.

15 статья. **Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы**

Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы Татарстан Республикасының тотрыклы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итү максатларында әзерләнә һәм, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемаларында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе, Идел буе федераль округының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе нигезләмәләренә һәм Россия Федерациясенең стратегик планлаштыруның тармак документлары нигезләмәләренә таяна.

7 бүлек. **Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм тикшереп тору**

16 статья. **Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау максаты һәм бурычлары**

1. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау максаты Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларындагы төп социаль-икътисадый һәм финанс күрсәткечләрен комплекслы бәяләү нигезендә гамәлгә ашырыла торган стратегик планлаштыру системасының эшләү нәтиҗәлелеген арттырудан, шулай ук стратегик планлаштыруда катнашучыларның Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының һәм муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсешенең планлаштырылган күрсәткечләренә билгеләнгән срокларда ирешү буенча эшләү нәтиҗәлелеген арттырудан гыйбарәт.



2. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглауның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше турында мәгълүматны җыю, системага салу һәм гомумиләштерү;

2) Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең планлаштырылган максатларына ирешү дәрәҗәсен бәяләү;

3) икътисад секторларын һәм дәүләт, муниципаль идарә өлкәләрен планлаштыру һәм программалаштыру кысаларында әзерләнә торган Татарстан Республикасы стратегик планлаштыру документларының нәтиҗәлелеген һәм эффектив булуын бәяләү;

4) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш максатларына ирешүнең план һәм факттагы дәрәҗәләренә эчке һәм тышкы институциональ факторларның, шартларның йогынтысын бәяләү;

5) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруның планлаштырылган һәм факттагы срокларының, нәтиҗәләренең һәм шушы документларны башкару өчен кирәкле ресурсларның туры килүен бәяләү;

6) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш дәрәҗәсен бәяләү, анализлау, ихтимал куркынычларны һәм хәтәрләрне ачыклау һәм аларны булдырмау өчен вакытында чаралар күрү;

7) стратегик планлаштыру системасының эшләү нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

3. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау нәтиҗәләрен чагылдыручы Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш өлкәсендәге документларына түбәндәгеләр керә:

1) «Россия Федерациясе субъектлары закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Президентының еллык хисабы;

2) Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы турында һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының еллык җыелма доклады.

4. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглауны башкару һәм Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау нәтиҗәләрен чагылдыручы документларны әзерләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау нәтиҗәләрен чагылдыручы документлар, дәүләт, коммерция, хезмәт урыны сере һәм законнар белән саклана торган башка сер турындагы белешмәләрдән тыш, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең стратегик планлаштыру документларын әзерләү өчен җаваплы органнарының рәсми сайтларында һәм стратегик планлаштыруның «Интернет» челтәрендәге һәркем файдалана алырлык мәгълүмат ресурсында урнаштырылырга тиеш.

17 статья. **Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору бурычлары**

1. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору бурычлары түбәндәгеләр:

1) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше турында мәгълүматны җыю, системага салу һәм гомумиләштерү;

2) максатны билгеләү, фаразлау, планлаштыру һәм программалаштыру кысаларында эшләнә торган Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларының сыйфатын бәяләү;

3) стратегик планлаштыру процессында кабул ителгән карарларның нәтиҗәлелеген һәм эффектив булуын бәяләү;

4) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш максатларына ирешүне бәяләү;

5) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш максатларына ирешүнең планлаштырылган һәм фактагы дәрәҗәсенә эчке һәм тышкы факторларның тәэсирен бәяләү;

6) стратегик планлаштыру системасының эшләү нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

2. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документын гамәлгә ашыруны тикшереп торучы орган тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына яисә Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документында планлаштырылган чараларны үткәрү яисә куелган күрсәткечләргә ирешү өчен җаваплы оешма җитәкчесенә мәгълүмат җибәрә.

3. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башкарыла.



8 бүлек. **Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыру**

18 статья. **Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыру**

1. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын әзерләү юлы белән башкарыла. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе нигезләмәләре, ресурслар белән тәэмин итү кирәклеген исәпкә алып, Татарстан Республикасы дәүләт программаларында төгәлләштерелә, моңа Россия Федерациясенең озак сроклы чорга бюджет фаразында һәм Татарстан Республикасының озак сроклы чорга бюджет фаразында билгеләнгән ресурслар белән тәэмин итү дә керә.

2. Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеш стратегиясенең төп нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары комплексы һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеге Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планына кертелә.

3. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт программалары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлегенә кертелә.

4. Татарстан Республикасының һәр дәүләт программасын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге ел саен бәяләнә. Күрсәтелгән бәяләүне үткәрү тәртибе һәм аның критерийлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын үтәү барышы турында еллык хисап әзерли.

9 бүлек. **Йомгаклау нигезләмәләре**

19 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын

әзерләү һәм корректировкалау, Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм тикшереп тору тәртибен билгели торган норматив хокукый актлар кабул итәргә, Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын Федераль законның 47 статьясында билгеләнгән сроклар нигезендә әзерләүне тәэмин итәргә тиеш.

3. Әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр кабул ителгән стратегик планлаштыру документлары билгеләнгән сроклары тәмамланганчы гамәлдә дип санала.

4. Татарстан Республикасы дәүләт программалары гамәлдә булу чорлары тәмамланганчы гамәлгә ашырыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 16 марты
№ 12-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 203. Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Россия Федерациясенең Торак кодексы нигезендә Татарстан Республикасында социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча (алга таба – наем шартнамәсе) гражданнарга торак урыннар бирүнең аерым мәсьәләләрен җайга сала, гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемен ачыклау һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләренең хакын билгеләү тәртибен нигезли һәм гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының кеременең һәм



аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен билгеләү тәртибен ачыклый.

2 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

Наем шартнамәләре буенча торак урыннар Россия Федерациясенең Торак кодексында билгеләнгән нигезләргә ярашлы рәвештә торак урыннарга мохтаҗлар дип танылган гражданнарга һәм башка федераль законда, Россия Федерациясе Президенты указында, Татарстан Республикасы законында яисә җирле үзидарә органының вәкиллекле органы актында билгеләнгән нигезләргә ярашлы рәвештә наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип танылган гражданнарга түбәндәге очракларда бирелергә мөмкин:

1) гражданның һәм аның белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының кереме һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләренең хакы әлеге Законның 5 статьясы нигезендә билгеләнә торган максималь күләмнән артып китмәсә;

2) граждан «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә аз керемле дип танылмаган булса һәм аз керемле дип тану өчен нигезләргә ия булмаса.

3 статья. **Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен, шул исәптән әлеге исәпкә кую, исәпкә куюдан баш тарту, аннан төшереп калдыру тәртибен билгеләү;

2) наемга бирүчеләр Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, әлеге органнар тарафыннан хокук бирелгән оешмалар яисә Россия Федерациясе Торак кодексының $91^{2}$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән һәм мондый органнар тарафыннан төзелгән оешмалар булган очракларда, гражданнарның наем шартнамәсе буенча торак урын бирү турында гаризаларын наемга бирүчеләр тарафыннан исәпкә алу тәртибен билгеләү;

3) социаль файдаланудагы наем йортларын һәм аларны төзү өчен бирелгән яисә билгеләнгән җир кишәрлекләрен исәпкә алу тәртибен билгеләү;

4) барлык урыннары Татарстан Республикасы милкендә булган наем йортлары белән һәм наем йортлары булган, Татарстан Республикасы милкендә саналган торак йортлар белән идарә итү тәртибен раслау;

5) әгәр наемга бирүчеләр Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, әлеге органнар тарафыннан хокук бирелгән оешмалар яисә Россия Федерациясе Торак кодексының $91^2$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән һәм мондый органнар тарафыннан төзелгән оешмалар булса, торак урынны наем шартнамәсе буенча наемга алган өчен түләү күләмен билгеләү;

6) торак урынны наем шартнамәсе буенча наемга алган өчен түләүнең максималь күләмен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре өчен дифференциация ясап билгеләү;

7) Татарстан Республикасы милкендәге торак урыннарны наем шартнамәләре буенча наемга бирергә хокуклы оешмаларның мондый шартнамәләрне төзүгә һәм үтәүгә карата Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәүүтәмәвен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

8) Россия Федерациясе Торак кодексында һәм әлеге Законда каралган башка төрле вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә җирле үзидарә органнарының вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемен һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләренең хакын билгеләү;

2) гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзалары кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен билгеләү;

3) җирле үзидарә органнары, әлеге органнар тарафыннан хокук бирелгән оешмалар яисә Россия Федерациясе Торак кодексының $91^2$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән һәм мондый органнар тарафыннан төзелгән оешмалар наемга бирүчеләр булса, гражданнарның наем шартнамәсе буенча торак урын бирү турында гаризаларын наемга бирүчеләр тарафыннан исәпкә алу тәртибен билгеләү;



4) гражданнарның наем шартнамәсе буенча торак урын бирү турында гаризаларын исәпкә алу тәртибен Россия Федерациясе Торак кодексының $91^{14}$ статьясындагы 5 өлешенең 3 пунктында күрсәтелгән наемга бирүчеләр белән килештерү кагыйдәләрен билгеләү;

5) наем шартнамәләре буенча торак урын бирелүгә мохтаҗ гражданнарның исәбен алып бару;

6) наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынның, бер кешегә исәпләгәндә, гомуми мәйданы күләмен билгеләү (торак урынның гомуми мәйданы күләме Россия Федерациясе Торак кодексының 58 статьясындагы нигезләмәләрне исәпкә алган торак урын бирү нормасыннан кимрәк була алмый);

7) барлык урыннары муниципаль берәмлек милкендә булган һәм, наем йортлары булып, муниципаль берәмлек милкендәге торак йортлар булган наем йортлары белән идарә итүнең тәртибен билгеләү;

8) социаль файдаланудагы наем йортларын һәм җир турындагы законнар нигезендә мондый йортлар төзү өчен бирелгән яисә билгеләнгән җир кишәрлекләрен социаль файдаланудагы наем йортларының муниципаль реестрында исәпкә алуны гамәлгә ашыру;

9) җирле үзидарә органнары, әлеге органнар тарафыннан хокук бирелгән оешмалар яисә Россия Федерациясе Торак кодексының $91^2$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән һәм мондый органнар тарафыннан төзелгән оешмалар наемга бирүчеләр булса, торак урынны наем шартнамәсе буенча наемга алган өчен түләү күләмен билгеләү;

10) Россия Федерациясе Торак кодексының $91^{14}$ статьясындагы 5 өлешенең 3 пунктында күрсәтелгән наемга бирүчеләргә торак урынны наем шартнамәсе буенча наемга алган өчен түләү күләмен килештерү;

11) муниципаль берәмлек милкендәге торак урыннарны наем шартнамәләре буенча наемга бирергә хокуклы оешмаларның мондый шартнамәләрне төзүгә һәм үтәүгә карата Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәүүтәмәвен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

12) наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар исәбенә куелган гражданнарга наем шартнамәләре буенча бирелә алган торак урыннарның саны турында хәбәр итүнең тәртибенә, рәвешенә һәм срокларына карата (шул исәптән белешмәләр исемлегенә, аларны бирү ешлыгына, рәвешенә һәм

урынына, мәгълүмат урнаштыру ешлыгына, рәвешенә һәм урынына карата) таләпләрне билгеләү;

13) Россия Федерациясе Торак кодексында һәм әлеге Законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

### 5 статья. Һәр гаилә әгъзасы яисә ялгыз яшәүче граждан кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен билгеләү тәртибе

1. Һәр гаилә әгъзасы яисә ялгыз яшәүче граждан кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләме әлеге Законга кушымта итеп бирелгән Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү методикасы нигезендә аныклана.

2. Һәр гаилә әгъзасы яисә ялгыз яшәүче граждан кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләме мондый гаилә әгъзаларына һәм мондый гражданга тиешле муниципаль берәмлек территориясендә үз акчаларына, торак урын сатып алуга кредит яисә заем исәбеннән торак урынны милеккә сатып алырга мөмкинлек бирә торган күләмнән артып китә алмый.

3. Һәр гаилә әгъзасы яисә ялгыз яшәүче граждан кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен яңадан карау елга бер тапкыр башкарыла.

### 6 статья. Һәр гаилә әгъзасы яисә ялгыз яшәүче граждан кеременең күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган керем төрләре

Наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында һәр гаилә әгъзасы яисә ялгыз яшәүче граждан кеременең күләмен исәпләгәндә һәр гаилә әгъзасы яисә ялгыз яшәүче граждан тарафыннан акчалата һәм әйберләтә алынган барлык керем төрләре дә исәпкә алына, шул исәптән:

1) законнар нигезендә уртача хезмәт хакын хисаплаганда исәпкә алына торган, хезмәт өчен түләү системасында каралган барлык түләүләр;

2) хезмәт законнарында каралган очракларда сакланып кала торган уртача хезмәт хакы;



3) дәүләт яисә җәмәгать бурычларын башкару вакытында дәүләт органы яисә җәмәгать берләшмәсе тарафыннан түләнә торган компенсация;

4) эштән җибәрелгәндә түләнә торган эштән китү пособиесе, отставкага чыккандагы компенсация, оешма бетүгә, штатлар саны яисә хезмәткәрләр штаты кыскартылуга бәйле рәвештә эштән җибәрелгәндә эшкә урнашу чорына сакланып кала торган хезмәт хакы;

5) барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан, бюджеттан тыш дәүләт фондларыннан һәм башка чыганаклардан социаль түләүләр, аларга түбәндәгеләр керә:

а) пенсияләр, компенсация түләүләре (хезмәткә яраксыз гражданнарны тәрбияләүче хезмәткә яраклы эшләмәүче затларга түләнә торган компенсация түләүләреннән тыш) һәм пенсионерларны ай саен өстәмә матди тәэмин итү;

б) отставкага киткән судьяларны гомер буена ай саен тәэмин итү;

в) стипендияләр, шул исәптән студентларга дәүләт академия стипендиясе, студентларга дәүләт социаль стипендиясе, бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге бүлектә укучы аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендияләре, мәгариф турында Россия Федерациясе законнарында каралган башка стипендияләр һәм акчалата түләүләр;

г) эшсезлек буенча пособие, эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм башка түләүләр, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри әзерлек, яңадан әзерлек һәм квалификация күтәрү чорында гражданнарга түләнә торган стипендия һәм матди ярдәм, җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарга аларның вакытлыча эшләрдә катнашу чорында түләүләр, шулай ук 14 яшьтән алып 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарга аларның вакытлыча эшләрдә катнашу чорында түләүләр;

д) вакытлыча хезмәткә яраксыз булу буенча пособие, йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие, шулай ук йөклелекнең башлангыч срокларында медицина оешмаларында исәпкә баскан хатын-кызларга бер тапкыр түләнә торган пособие;

е) балага айлык пособие;

ж) яшь ярымга җиткәнче баланы карау буенча отпуск чорына айлык пособие һәм хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы һәм өч яшькә җиткәнче бала карау буенча отпуск ялындагы гражданнарга айлык компенсация түләүләре;

з) эшләмәскә мәҗбүр булган яисә белгечлек буенча эшкә урнашу мөмкинлеге булмау сәбәпле эшкә урнаша алмаган һәм билгеләнгән тәртиптә эшсезләр буларак танылган урыннарда ирләре белән яшәгән чорда, шулай ук, әгәр дә медицина оешмасы биргән бәяләмәдә балалары 18 яшькә җиткәнче икенче бер кешенең карап торуына мохтаҗ дип билгеләнгән булса, иренең хәрби хезмәт итү урынында яшәү шартларына бәйле рәвештә хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары балаларының сәламәтлегe торышы буенча эшләмәскә мәҗбүр булган чорда контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрнең хатыннарына айлык пособие;

и) аеруча ерак гарнизоннардагы һәм җирлекләрдәге Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының һәм Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының җинаять-үтәү системасы учреждениеләренең рядовой һәм җитәкчелек составы затларының эшләмәүче хатыннарына аларны хезмәткә урнаштыру мөмкинлеге булмаганда айлык компенсация түләве;

к) производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәргә бәйле авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү буенча айлык иминият түләүләре;

л) әлеге пунктта күрсәтелгән барлык түләү төрләренә карата арттырып түләүләр, өстәмә түләүләр һәм Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан билгеләнгән башка социаль түләүләр;

6) гаиләнең (аның аерым әгъзаларының) яисә ялгыз яшәүче гражданның милек хокукындагы мөлкәтеннән алынган керемнәр, аларга түбәндәгеләр керә:

а) күчемсез мөлкәтне (җир кишәрлекләрен, йортларны, фатирларны, дачаларны, гаражларны), транспорт һәм башка төрле механика чараларын, продуктларны эшкәртү һәм саклау чараларын сатудан һәм арендага (субарендага, наемга, өстәмә наемга) бирүдән алынган керемнәр;

б) шәхси ярдәмче хуҗалык уңышларын һәм продукцияләрен (күпьеллык утыртмалар, бакча продукциясе, продукция буларак һәм күрсәтү өчен үстерелгән хайваннар, кошлар, кыйммәтле мехлы җәнлекләр, умарта кортлары, балык) сатудан алынган керемнәр. Күрсәтелгән керемнәргә, җир кишәрлегеннән алынып, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан тарафыннан шәхси куллану өчен файдаланылган уңышлар һәм продукция керми;

7) гаиләнең яисә ялгыз яшәүче гражданның башка керемнәре, аларга түбәндәгеләр керә:

а) хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының



җинаять-үтәү учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясенең таможня органнары һәм хокук саклау хезмәтенең бүтән органнары хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән даими башкарыла торган өстәмә түләүләр һәм азык-төлек белән тәэмин ителү (азык-төлек паегына алмашка акчалата компенсация);

б) хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарыннан, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының җинаять-үтәү учреждениеләреннән һәм органнарыннан, Россия Федерациясенең таможня органнарыннан, хокук саклау хезмәтенең бүтән органнарыннан эштән киткәндә бер тапкыр бирелә торган пособие;

в) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча эшләр өчен түләү;

г) эш бирүчеләр тарафыннан үзләренең хезмәткәрләренә, шул исәптән инвалидлык яисә яше буенча пенсиягә чыгу сәбәпле эштән киткән элекке хезмәткәрләренә күрсәтелә торган матди ярдәм;

д) авторлык хокукы һәм катнаш хокуклар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә, шул исәптән авторлыкны мирас итеп алу шартнамәләре буенча алына торган авторлык түләүләре;

е) крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат буларак төзелгән хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәрне дә кертеп, эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүдән алынган керемнәр;

ж) акцияләрдән алынган керемнәр һәм оешма милкенә идарә итүдә катнашудан алынган башка керемнәр;

з) алына торган алиментлар;

и) банк кертемнәре буенча процентлар;

к) мирас итеп алына торган яисә бүләк ителгән акчалар;

л) гражданнарга социаль ярдәм чаралары буларак бирелә торган һәм торак урыннар, коммуналь яисә транспорт хезмәте күрсәтүләр өчен түләүгә бәйле акчалата түләүләр;

м) торак урын, коммуналь һәм транспорт хезмәте күрсәтүләр өчен түләү буенча гражданнарга бирелә торган, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалары тарафыннан билгеләнгән, гражданнарга түләүне киметү рәвешендә бирелгән ташламаларның һәм социаль ярдәм чараларының акча эквивалентлары;

н) торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен аерым категорияләрдәге гражданнарга түләнә торган компенсацияләр;

о) опекага алынучыны карап торган өчен опекунга (попечительгә) бирелә торган акчалар;

п) гариза бирүченең яисә аның гаилә әгъзаларының мәгариф оешмаларында белем алуы өчен түләүгә тотылган теләсә нинди чыганаклардан алынган акчалар (гариза бирүченең яисә аның гаилә әгъзаларының үз акчаларыннан тыш);

р) түбәндәге законнар нигезендә билгеләнгән төрле категорияләрдәге гражданнарга айлык акчалата түләүләрнең һәм компенсацияләрнең суммалары:

«Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы;

«Ветераннар турында» Федераль закон;

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон;

«Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» Федераль закон;

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Федераль закон;

с) күрсәтелгән дәүләт социаль ярдәме суммалары.

**7 статья. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган керем күләмен ачыклаганда исәпкә алынмый торган керем төрләре**

1. Гражданнарның керемнәренә түбәндәгеләр керми:

1) кешенең гомеренә һәм сәламәтлегенә, аның шәхси мөлкәтенә һәм аның гаилә әгъзалары белән уртак милектәге мөлкәтенә китерелгән зыянны каплау өчен бер тапкыр түләнә торган иминият түләүләре, шулай ук дәүләт медик-социаль экспертиза хезмәте учреждениесе карары нигезендә медицина, социаль һәм һөнәри реабилитацияләүгә өстәмә чыгымнар белән бәйле айлык суммалар;

2) дәүләт социаль ярдәме турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әйберләтә ярдәм рәвешендә күрсәтелә торган дәүләт социаль ярдәме;



3) эшсез гражданнарга халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте тәкъдиме буенча башка җиргә эшкә (укуга) юллану сәбәпле түләнә торган матди чыгым компенсацияләре;

4) күмү өчен пособие;

5) төрле категорияләрдәге гражданнарга түбәндәге законнар нигезендә түләнә торган еллык компенсацияләр һәм берьюлы (бер тапкыр) бирелә торган пособиеләр:

а) «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы;

б) «Ветераннар турында» Федераль закон;

в) «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон;

г) «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» Федераль закон;

д) «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Федераль закон.

2. Гаиләнең яисә ялгыз яшәүче гражданның кеременнән алар тарафыннан түләнгән алимент суммалары алына.

3. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган keremne исәпләгәндә, аларның булу урыннары буенча түбәндәгеләр тарафыннан алынган керемнәр исәпкә алынмый:

1) сержантлар, старшиналар, солдатлар яисә матрослар буларак чакырылу буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр, шулай ук хәрби профессиональ белем бирү оешмаларында һәм югары белемнең хәрби белем бирү оешмаларында белем алучы һәм хәрби хезмәтне узу турында контрактлар төземәгән хәрби хезмәткәрләр;

2) иректән мәхрүм ителү рәвешендә җәза үтәүче затлар, сак астына алу рәвешендә чикләү чарасы кулланылган, шулай ук суд карары буенча мәҗбүри дәваланудагы затлар;

3) интернат тибындагы учреждениеләрдә тулысынча дәүләт тәэминатында яшәүче затлар;

4) хәбәрсез югалган һәм эзләү гамәлләре башкарыла торган затлар.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән гражданнар өчен аларның кайда булуларына бәйсез рәвештә алына торган керемнәр (банклардагы, бүтән кредит учреждениеләрендәге кертемнәр буенча алынган керемнәр, күчмә һәм (яисә) күчемсез мөлкәтне наемга яисә өстәмә наемга бирүдән алынган керемнәр, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән башка керемнәр) исәпкә алына.

### 8 статья. Аерым категорияләрдәге гражданнарның керемнәрен билгеләү үзенчәлекләре

1. Хезмәткә яраклы балигъ булган гражданнарны хисап чоры дәвамында керемнәре булмаган дип тану, алар гаризада үз керемнәрен, шул исәптән хезмәт һәм (яисә) индивидуаль эшкуарлык эшчәнлегеннән кергән керемнәрен, хисап чорының бер ае буенча да раслый алмаган яки мөстәкыйль рәвештә декларация тутыра алмаган очракларда яисә үзләренең нульгә тигез керемнәрен раслый торган документларны тапшырганда, җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бу вакытта хисап чоры булып Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә наем шартнамәләрен төзүгә хокукы булган гражданнарны исәпкә кую (алга таба – наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗларны исәпкә кую) турында гариза бирелгән айдан алда килгән бер елга тигез чор санала.

2. Урта һөнәри яисә югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучылардан тыш, хисап чоры дәвамында керемнәре булмаган дип танылган хезмәткә яраклы балигъ булган гражданнар гаилә әгъзаларының гомуми составыннан чыгарыла. Бу очракта гаиләнең гомуми уртача айлык кереме гаилә әгъзаларының гомуми санына түгел, ә хисап чорында керемнәре булмаган, хезмәткә яраклы балигъ булган гаилә әгъзалары санына киметелгән санга бүленә.

3. Әгәр гражданнар, хезмәт һәм индивидуаль эшкуарлык эшчәнлегеннән алынган керемнәрдән тыш, үзләренең нинди дә булса керемнәрен документлар нигезендә раслый алмаса, аларга гаризада мондый керемнәренә мөстәкыйль декларация тутыру хокукы бирелә.

4. Салым салуның һәм гомуми, һәм гадиләштерелгән системасын, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр өчен салым салу системасын (бердәм авыл хуҗалыгы салымы) кулланучы индивидуаль эшкуарларның керемнәрен индивидуаль эшкуарның керемнәрне һәм чыгымнарны, шулай ук хуҗалык операцияләрен исәпкә алу кенәгәсендәге белешмәләр белән расларга кирәк.



5. Әгәр салым салу объекты тиешле чыгымнар зурлыгына киметелмәгән керемнәрдән гыйбарәт булса, ул вакытта индивидуаль эшкуарлар хисап чорындагы чыгымнарны раслый торган беренчел исәпкә алу документларын күрсәтәләр.

6. Аерым төр эшчәнлек өчен булырга мөмкин керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын кулланучы индивидуаль эшкуарларның керемнәре үткән салым чоры өчен салым декларацияләренең декларацияләрне кабул итү турында салым органы тамгасы булган күчермәләре белән раслана.

7. Гражданның һәр гаилә әгъзасының керемен исәпләп чыгарганда, хезмәт хакын, хезмәт өчен түләү системасында каралган һәм ай буе эшләү нәтиҗәләре буенча түләнә торган компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне, айлык социаль түләүләрне һәм башкаларны да үз эченә алган барлык керемнәрнең суммасы хисап чорына керүче фактта алу аенда исәпкә алына.

8. Компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне үз эченә алган хезмәт хакын исәпләп чыгаруга һәм түләүгә башка сроклар билгеләнгәндә, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр белән бергә алынган хезмәт хакы суммасы әлеге хезмәт хакы исәпләнгән айлар санына бүленә һәм гражданның хисап чорына туры килә торган айлар керемнәрендә исәпкә алына.

9. Вакытлы хезмәт шартнамәләре буенча башкарыла торган сезонлы, вакытлыча һәм башка төрле эшләр өчен түләү, граждан-хокукый характердагы шартнамәләрне үтәүдән алынган керемнәр, шулай ук эшкуарлык һәм башка төр эшчәнлектән алынган керемнәр суммалары аларны алган айлар санына бүленә һәм гражданнарның хисап чорына туры килә торган айлар керемнәрендә исәпкә алына.

10. Гражданнар – крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзалары тарафыннан алынган керемнәр әлеге хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган уңышлардан, продукциядән һәм керемнәрдән файдалану турында крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзалары арасында законнарда билгеләнгән тәртиптә төзелгән килешүдә (шартнамәдә) күрсәтелгән күләмнәреннән чыгып исәпкә алына.

11. Күчемсез һәм башка төр мөлкәтне арендага (наемга, субарендага, өстәмә наемга) бирүдән алынган керемнең суммасы керем алынган айлар санына бүленә һәм гражданнарның хисап чорына туры килә торган айлар керемнәрендә исәпкә алына.

12. Гражданнар тарафыннан белешмәләрдә күрсәтелгән керемнәр законнар нигезендә барлык салымнарны һәм җыемнарны түләгәннән соң кала торган күләмдә исәпкә алына.

9 статья. **Аерым категорияләрдәге гражданнар керемнәрен исәпкә алуның һәм мөлкәтләренең хакын билгеләүнең үзенчәлекләре**

1. Ялгыз яшәүче ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, бөтен хисап чорында яисә аның бер өлешендә мәгариф һәм башка оешмаларда, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында, тәрбиягә алган гаиләләрдә, гаилә тибындагы балалар йортларында яшәгән балаларның керемнәре аларның күрсәтелгән оешмаларда яшәгән айлары өчен тиешле социаль-демографик төркемгә туры килә торган яшәү минимумына тигез дип санала.

2. Хисап чорында сержантлар, старшиналар, солдатлар яисә матрослар буларак чакырылыш буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр, шулай ук хәрби һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белемнең хәрби белем бирү оешмаларында белем алучы һәм хәрби хезмәт узу турында контракт төземәгән хәрби хезмәткәрләр; ирегеннән мәхрүм ителү рәвешендә җәза үтәүче затлар; сак астына алу рәвешендә чикләү чарасы күрелгән затлар; суд карары буенча мәҗбүри дәваланудагы затлар; законлы көченә кергән суд карары нигезендә кайда булуы билгесез дип танылган затлар; интернат тибындагы учреждениеләрдә тулысынча дәүләт тәэминатында яшәүче затлар арасыннан булган ялгыз яшәүче гариза бирүчеләрнең булу урыннары буенча алынган керемнәре, әлеге статьяның 3 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, тиешле социаль-демографик төркем өчен яшәү минимумына тигез дип танылa.

3. Әлеге статьяның 1, 2 өлешләрендә күрсәтелгән затлар законлы нигезләрдә аларныкы булган күчемсез мөлкәтнең аларның файдалануына күчә алмавы турындагы белешмәләрне (суд бәхәсләре, билгеләнгән тәртиптә хокук теркәлгән торак урынга чынбарлыкта кереп урнашу мөмкин булмау, күрсәтелгән затка караган мөлкәт өлешен сату мөмкин булмау очракларында, бүтән төрле чикләүләр булганда) раслаган очракларда, аларныкы булган күчемсез мөлкәтнең хакы нульгә тигез дип танылa. Мөлкәттән файдалану мөмкин булмавы турында белешмәләрне раслау гражданның булу урыны буенча опека һәм попечительлек органнары тарафыннан яисә тиешле документлар нигезендә җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.



10 статья. **Һәр гражданга туры килә торган керем күләмен билгеләү**

1. Һәр гражданга туры килә торган керем күләме әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә тапшырылган документлар һәм белешмәләр нигезендә җирле үзидарә органы тарафыннан исәпләп чыгарыла.

2. Һәр гаилә әгъзасының яисә гариза биргән ялгыз яшәүче гражданның уртача айлык кереме аның хисап чорында алынган керемнәре суммасын аның әлеге керемнәре булган айлар санына бүлү юлы белән исәпләп чыгарыла. Һәр гаилә әгъзасының уртача айлык керемнәре суммасы хисап чорында гаиләнең уртача айлык гомуми керемен тәшкил итә.

3. Хисап чорында һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык гомуми керем гаиләнең хисап чорындагы уртача айлык гомуми керемен гариза биргән гражданның гаилә әгъзалары санына бүлеп исәпләп чыгарыла.

4. Хисап чорында һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык керем күләмен хисап чорындагы айларның санына һәм гаилә әгъзаларының санына тапкырлау хисап чорында гаиләнең гомуми керемен тәшкил итә.

11 статья. **Гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында исәпкә алына торган мөлкәт**

1. Гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану өчен гражданнарның милкендә булган, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә салым салынырга тиешле мөлкәтнең хакы исәпкә алына.

2. Гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында исәпкә алына торган мөлкәткә түбәндәгеләр керә:

1) торак йортлар, фатирлар, дачалар, гаражлар һәм бүтән төзелмәләр, биналар һәм корылмалар;

2) законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән автомобильләр, мотоцикллар, мотороллерлар, автобуслар һәм башка үзйөрешле машиналар, шулай ук пневматик һәм чылбыр белән йөрешле механизмнар, самолетлар, вертолетлар, теплоходлар, яхталар, паруслы суднолар, катерлар, карда йөрү машиналары, моточаналар, моторлы көймәләр, гидроцикллар, үзе йөрми торган (буксирга алына торган суднолар) һәм башка су һәм һава транспорт чаралары;

3) торак-төзелеш, гараж һәм дача кулланучылар кооперативларындагы пай җаелмалары;

4) мөлкәт һәм җир өлешләренең (пайларының) хакы, бәяләрендә күрсәтелгән валютадагы кыйммәтләр һәм кыйммәтле кәгазьләр;

5) территориясендә Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә җир салымы кертелгән муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре.

12 статья. **Гражданнарның гомуми өлеш милкендә яисә гражданнарның һәм юридик затларның гомуми өлеш милкендә йә гомуми уртак милектә булган мөлкәтне исәпкә алу үзенчәлекләре**

Салым салу объекты дип танылган мөлкәт берничә гражданның гомуми өлеш милкендә яисә гражданнарның һәм юридик затларның гомуми өлеш милкендә булган очракларда, шулай ук салым салу объекты дип танылган мөлкәт берничә физик затның гомуми өлеш милкендә булса, гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип таныганда, салымны түләүчесе мондый граждан һәм (яисә) аның гаилә әгъзалары булган мөлкәт салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә исәпкә алынырга тиеш.

13 статья. **Хисап чорында сатылган мөлкәтне исәпкә алу үзенчәлекләре**

Әгәр салым салынырга тиешле һәм гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану өчен исәпкә алына торган мөлкәт исемлегенә керүче мөлкәт гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче гариза биргән граждан тарафыннан хисап чорында сатылган булса, сатылган мөлкәтнең хакы хисап чоры дәвамында булган мөлкәт хакы буларак исәпкә алына, моңа гариза биргән гражданнар тарафыннан тапшырыла торган тиешле документлар белән расланган мәҗбүри сату (ашыгыч медицина дәвалануы, кыйммәтле дарулар һ.б. өчен түләү) очраклары керми.

14 статья. **Гражданнар милкендәге күчемсез мөлкәтнең хакын билгеләү**

1. Гражданнар милкегендәге күчемсез мөлкәтнең хакы күчемсез мөлкәтне кадастр исәбенә куюны һәм дәүләт кадастрын алып баруны башкара торган органнан тиешле салым органнары



алган мәгълүматлар нигезендә җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә. Граждан яисә җирле үзидарә органы күчемсез мөлкәтнең кадастр хакы белән килешмәгән очракта, мөлкәтнең базар хакы кулланыла, шул ук вакытта күчемсез мөлкәтне бәяләү буенча тиешле чыгымнарны кадастр бәясе белән килешмәгән зат каплый.

2. Җир кишәрлекләренең хакы җирле үзидарә органы тарафыннан җирнең кадастр бәясе турындагы мәгълүматлар нигезендә билгеләнә.

15 статья. **Гражданнарның башка төр мөлкәтләре хакын билгеләү**

1. Гражданнар милкендәге һәм исәпкә алынырга тиешле транспорт чараларының хакы гражданнарның үз хисабына үткәрелә торган транспорт чараларын бәяләү турындагы бәяләү эшчәнлеге субъектының хисабы нигезендә җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә.

2. Торак-төзелеш, гараж һәм дача кулланучылар кооперативларындагы пай җыелмаларының хакын билгеләү гариза биргән граждан тарафыннан тапшырылган һәм торак-төзелеш, гараж һәм дача кулланучылар кооперативлары таныклаган белешмәләргә таянып башкарыла.

16 статья. **Наем шартнамәләре буенча торак урыннар алуга хокукны кабат раслау максатларында гражданнарның керемнәре һәм мөлкәтләренең хаклары күләмен яңадан бәяләү**

1. Наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар исәбенә алынган гражданнарның керемнәрен һәм мөлкәтләренең хакын яңадан бәяләү, наем шартнамәләре буенча торак урыннар алуга аларның хокукын раслау максатларында, җирле үзидарә органы тарафыннан ел саен 1 гыйнвардан алып 1 майга кадәр әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

2. Наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар исәбенә куелган гражданнарның керемнәрен һәм мөлкәтләренең хакларын яңадан бәяләүне уздыру өчен, әгәр гражданнар үз теләкләре белән тиешле документларны тапшырмаган булсалар, җирле үзидарә органы 1 апрельгә кадәр түбәндәге документларны соратып алырга тиеш:

1) мөлкәткә хокукларны дәүләт исәбенә алу һәм теркәү органнарыннан һәм тиешле органнардан гражданнарның милек хокукындагы салым салынырга тиешле күчемсез һәм күчемле

мөлкәтләренә ия булуларының хокукый нигезләрен раслый торган документларның күчермәләрен;

2) узган салым чорындагы керемнәре турында салым декларацияләренең салым органы тамгасы куелган күчермәләрен яисә гражданнарны аз керемле дип тану турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган гражданнар керемнәрен раслый торган башка документларны;

3) әлеге Законның 17 статьясындагы 1 өлешендә каралган документларны (граждан тарафыннан тапшырыла торган гаризадан тыш).

3. Наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар исәбенә алынган гражданнарның керем күләмен һәм мөлкәт хакын яңадан бәяләү түбәндәге рәвештә башкарыла:

1) гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемнең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләме кимегәндә, гражданнарны исәпкә алу вакытына гамәлдә булган күрсәткечләр кулланыла;

2) гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының кереме һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләме артканда керемнең һәм мөлкәт хакының яңа билгеләнгән максималь күләме кулланыла.

4. Керемнәр һәм мөлкәт хакы күләме керемнең һәм мөлкәт хакының максималь күләменә тигез яисә аннан арткан очракта, гражданнар наем шартнамәләре буенча торак урыннар алу хокукын югалта.

### 17 статья. **Гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен кирәкле документлар исемлеге, шулай ук аларны тапшыру тәртибе**

1. Гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен түбәндәге документлар кирәк:

1) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән форма буенча гариза, ул граждан белән бергә даими яшәүче хокукка сәләтле барлык гаилә әгъзалары тарафыннан имзалана;

2) гражданның һәм аның белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының паспортлары яисә шәхесне таныклаучы башка документларның күчермәләре;



3) гражданның гаилә составы турындагы документларның (туу турында таныклык, язылышу турында таныклык, уллыкка алу (кызлыкка алу) турында карар, гаилә әгъзасы итеп тану турында суд карары һ.б.); күчермәләре

4) йорт кенәгәсеннән өземтә;

5) граждан һәм аның гаилә әгъзалары яши торган торак урыннан файдалану хокукын раслаучы документларның (шартнамә, ордер, торак бинаны бирү турында карар һәм башка төрле документлар) күчермәләре;

6) гаилә әгъзаларының даими яшәү урыны буенча милек хокукында торак урыннар булу яисә булмау турында дәүләт теркәве органнарыннан белешмә, ул гаризаны бирү вакытына кадәрге биш ел өчен гариза бирүченең хокукка сәләтле һәр гаилә әгъзасы тарафыннан тапшырыла.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1, 2 һәм 3 пунктларында, әлеге Законның 8 (5 өлешеннән тыш), 13 һәм 15 статьяларында күрсәтелгән документлар гражданнар тарафыннан тапшырыла.

3. Әлеге Законның 1 өлешендәге 4 — 6 пунктларында һәм 15 статьясында күрсәтелгән документлар гражданнар тарафыннан үз теләге белән тапшырылырга мөмкин, ә тапшырылмаган очракта, күрсәтелгән документлар җирле үзидарә органы тарафыннан дәүләт органнарында, җирле үзидарәнең башка органнарында йә аларның буйсынуындагы оешмаларда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып алына.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән документлар төп нөсхәләрендә дә, гаризаны бирү урыны буенча җирле үзидарә органы яисә тиешле документны биргән оешмалар тарафыннан таныкланган йә нотариаль таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла.

5. Җирле үзидарә органнары сорату нигезендә тапшырылган һәм алынган документларны һәм белешмәләрне дәүләт хакимияте органнарына, салым һәм таможня органнарына, башка оешмаларга рәсми соратулар җибәрү юлы белән тикшерергә хокуклы.

6. Гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар тапшырылган документларның һәм белешмәләрнең дөреслеге өчен законнар нигезендә җаваплы була. Гаризада керемнәр һәм мөлкәтләр турында тапшырылган белешмәләрне җирле үзидарә органы тарафыннан салым, таможня һәм башка органнарда тикшерүгә карата гражданның һәм аның балигъ булган гаилә әгъзаларының ризалыгы белдерелгән булырга тиеш.

18 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән башлап өч ай эчендә әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 16 марты
№ 13-ТРЗ

«Социаль файдаланудагы торак фондының
торак урыннарына наем шартнамәләре буенча
гражданнарның торак урыннары алу
хокукларын гамәлгә ашыру турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

## Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган keremнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү методикасы

1. Наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү нормасы буенча торак урыннар алуның базар хакын исәпләү күрсәткече (алга таба – исәп күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ,
монда:

СЖ – исәп күрсәткече;
НП – муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;
РС – гаилә әгъзаларының саны;
РЦ – торак урындагы бер квадрат метрның муниципаль берәмлектәге уртача шартларга һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган, Татарстан Республикасында торак урыннарны алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар хакыннан артып китми торган уртача исәпләнгән базар бәясе.



2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме СЖ исәпләү күрсәткеченә тигез итеп кабул ителә.

Гражданның һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемененң максималь күләме түбәндәгечә билгеләнә:

1) торак урын сатып алуга ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган, СЖ исәпләү хакы буенча торак урын сатып алуга агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып, ул түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 – (1 + ПС)$^{-КП}$) / (0,25 х РС),
монда:

ПД – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләү хакы буенча торак урын сатып алуга агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;
СЖ – исәп күрсәткече;
ПС – кредит буенча бер айга процент ставкасы (унарлы вакланма);
КП – кредитның барлык срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);
РС – гаилә әгъзаларының саны;
0,7 – кредит суммасының фатир хакына карата нисбәте;
0,25 – кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма керемненә карата нисбәте;

2) торак урын сатып алуга ипотека кредиты алу мөмкинлеге булмаган муниципаль берәмлекләрдә – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм, социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урын алу чиратында уртача көтү вакытына тигез итеп карала торган муниципаль берәмлектә билгеләнгән уртача туплау чорын исәпкә алып, СЖ исәпләү хакы буенча торак урын сатып алу өчен акча туплауга кирәкле булган уртача айлык җыелма керем күләменнән чыгып. Бу вакытта тупланмаларның Татарстан Республикасында минималь куллану

бюджетының уртача зурлыгына тигез яисә аннан кимрәк керем алганда җыела алмавы исәпкә алына.

Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең максималь күләмен билгеләү өчен түбәндәге формула кулланыла:

а) социаль файдаланудагы торак фонды милекчесе үзенә караган урыннарны наемга бирүдән керем алуны планлаштырса:

ПД = (СЖ / ПН) / РС + ПБ х 1,02,
монда:

ПД – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең максималь күләме;
СЖ – исәп күрсәткече;
ПН – тупланмаларның билгеләнгән чоры (айлар саны);
РС – гаилә әгъзаларының саны;
ПБ – бер кешегә уртача айлык керемнең җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән минималь күләме (бер типтагы гаилә әгъзасына минималь куллану бюджеты);

б) социаль файдаланудагы торак фонды милекчесе үзенә караган урыннарны наемга бирүдән керем алырга ниятләмәсә (әгәр торак дәүләт һәм муниципаль торак фондларыннан бирелсә):

ПД = (СЖ / ПН) / РС + ПБ,
монда:

ПД – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык керемнең максималь күләме;
СЖ – наем шартнамәсе нигезендә торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакын исәпләү күрсәткече;
ПН – тупланмаларның билгеләнгән чоры (айлар саны);
РС – гаилә әгъзаларының саны;
ПБ – бер кешегә җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән уртача айлык минималь дәрәҗә (бер типтагы гаилә әгъзасына минималь куллану бюджеты).

3. Гаилә әгъзаларының яисә ялгыз яшәүче гражданның торак урын сатып алу өчен наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасыннан түбән булмаган күләмдәге җитми торган акчалары түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ПЖ = СЖ – И,



монда:

ПЖ – торак урын өчен акчаларга ихтыяҗ;
СЖ – исәп күрсәткече;
И – гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле, гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүдә мохтаҗлар категориясенә керткәндә исәпкә алына торган мөлкәт хакының күләме.

4. Ипотека кредиты алу мөмкинлеген бәяләү түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ПЛТ = ПЖ х ПС / (1 – (1 + ПС) $^{-КП}$),
монда:

ПЛТ – ипотека кредиты буенча ай саен түләнә торган сумма;
ПЖ – торак урын өчен акчаларга ихтыяҗ;
ПС – кредит буенча айлык процент ставкасы (унарлы вакланма);
КП – кредитның барлык срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны).

5. Гаиләнең ай саен, П/ДС, О/ДС, ПЖ/СЖ коэффициентларын кулланып, ПЛТ күләмендә кредит каплау мөмкинлеге:

1) П/ДС <= 30%,
монда:

П – заемга алучының торак өчен айлык чыгымнары, моңа төп бурыч буенча айлык түләү һәм ипотека кредиты буенча процентлар (ПЛТ) түләү, мөлкәткә салым буенча айлык түләүләр, күчемсез мөлкәтне иминләштерү, шулай ук заем алучының гомерен иминләштерү буенча айлык түләүләр дә керә;
ДС – гаиләнең уртача айлык җыелма кереме (керем салымын тотып калып);

2) О/ДС <= 40%,
монда:

О – турыдан-туры кредитлар (П) түләүгә, шулай ук заем алучының озак сроклы (кагыйдә буларак, бер елдан артык) башка йөкләмәләренә бәйле (куллану кредитларына, башка бурыч йөкләмәләренә, шулай ук алиментларга, тәрбиясендә булганнарны карап тотуга, сәламәтлекне медицина иминләштерүенә яисә

пенсия тупланмаларына (контрактлар һәм шартнамәләр нигезендә өстәмә рәвештә), күчемле һәм күчемсез мөлкәтне иминләштерүгә һәм башка төрле мәҗбүри даими түләүләргә бәйле) чыгымнарны исәпкә алган айлык мәҗбүри түләүләрнең гомуми суммасы;

ДС – гаиләнең уртача айлык җыелма кереме (керемгә салымны исәпкә алып).

6. Гаиләнең торак урын сатып алу өчен җитми торган акчаны туплый алу мөмкинлеге түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$\text{Н} = (\text{ДС} - \text{СПБ}) \times \text{ПН},$$

монда:

Н – билгеләнгән чорда гаиләнең мөмкин булган тупланмалары күләме;

ДС – гаиләнең уртача айлык җыелма кереме;

СПБ – гаиләгә исәпләгәндә уртача айлык минималь керем дәрәҗәсе (бер типтагы гаилә әгъзасына минималь куллану бюджеты күләмен гаилә әгъзалары санына тапкырлап исәпләнә);

ПН – тупланмаларның билгеләнгән чоры (айларда).

7. Гражданны наем шартнамәләре буенча торак урын алуга мохтаҗ дип тану турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) җитми торган акча күләме гаиләнең аны туплау мөмкинлегеннән артыграк булса ($\text{ПЖ} > \text{Н}$), ә гаиләнең бер әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме торак бина сатып алу яисә төзү өчен кредит алуны дәгъва кылырга мөмкинлек бирмәсә ($\text{П}/\text{ДС} > 30\%$ яисә $\text{О}/\text{ДС} > 40\%$) – гражданны наем шартнамәсе буенча торак урын алуга мохтаҗ дип тану турында карар кабул ителә;

2) гаиләнең акча туплау мөмкинлекләре җитми торган акча күләменә тигез яисә аннан артыграк булса ($\text{Н} >= \text{ПЖ}$) – гражданны наем шартнамәсе буенча торак урын алуга мохтаҗ дип танымау турында карар кабул ителә;

3) җитми торган акча күләме гаиләнең аны туплау мөмкинлегеннән артыграк булса ($\text{ПЖ} > \text{Н}$), ләкин гаилә торак бина сатып алуга яисә төзүгә кредит алуны дәгъва кыла алса ($\text{П}/\text{ДС} <= 30\%$, $\text{О}/\text{ДС} <= 40\%$), гражданны наем шартнамәсе буенча торак урын алуга мохтаҗ дип тану турында карар тиешле муниципаль берәмлектә торак урын сатып алуга яисә төзүгә торак кредитлары бирү базарының үсеш дәрәҗәсенә бәйле булырга мөмкин, ул:

а) торак сатып алуга кредит бирүне тәэмин итүче кредит оешмалары (ипотека, өлешләп төзү, торак-туплау кооперативлары һәм башкалар) булу-булмауга бәйле рәвештә;



б) торак кредитларын субсидияләү буенча региональ яисә муниципаль программалар булу-булмауга бәйле рәвештә;

в) банкның гариза биргән гражданга торак сатып алуга яисә төзүгә кредит бирү турында яисә кредит бирүдән баш тарту хакында конкрет карары белән билгеләнә.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 204. Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3; 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп, үзгәреш кертергә:

«федераль законнар нигезендә мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру;

иҗтимагый оешмалар катнашында мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет төзү һәм аның турында нигезләмә раслау;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында һәм дәүләт, муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре хакында мәгълүмат урнаштыру;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфаты турында хезмәт күрсәтүләрне алучыларның фикерләрен белдерүнең техник мөмкинлеген тәэмин итү.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда түбәндәге эчтәлекле $16^{1}$, $16^{2}$ , $16^{3}$ һәм $16^{4}$ пунктлар өстәргә:

«$16^{1}$) федераль законнар нигезендә медицина оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру;

$16^{2}$) сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын яклау буенча иҗтимагый берләшмәләр, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 76 статьясындагы 3 өлешенең таләпләренә туры килүче коммерциячел булмаган һөнәри медицина оешмалары (аларның вәкилләре) катнашында медицина оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет төзү һәм аның турында нигезләмә раслау;

$16^{3}$) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында һәм дәүләт, муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта медицина оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре хакында мәгълүмат урнаштыру;

$16^{4}$) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында медицина оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфаты турында пациентларның фикерләрен белдерүнең техник мөмкинлеген тәэмин итү;»;

2) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары сәламәтлек саклау өлкәсендәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен Федераль закон нигезендә гамәлгә ашыра.».

**3 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:



1) 4 статьяның 2 өлешендә түбәндәге эчтәлекле $13^{1}$, $13^{2}$ , $13^{3}$ һәм $13^{4}$ пунктлар өстәргә:

«$13^{1}$) федераль законнар нигезендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеге сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыра;

$13^{2}$) иҗтимагый оешмалар катнашында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеге сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет төзи һәм аның турында нигезләмә раслый;

$13^{3}$) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында һәм дәүләт, муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеге сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре хакында мәгълүмат урнаштыра;

$13^{4}$) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеге сыйфаты турында хезмәт күрсәтүләрне алучыларның фикерләрен белдерүнең техник мөмкинлеген тәэмин итә;»;

2) 19 статьяда:

а) 1 һәм 3 өлешләрдә «дәүләт аккредитациясе булган» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Кабул итүнең контроль саннары гавами конкурс нәтиҗәләре буенча бүленә һәм, әгәр әлеге статьяда башкасы билгеләнмәгән булса, урта һөнәри һәм югары белемнең дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программалары нигезендә белем бирү өчен һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең, әзерлек юнәлешләренең гомумиләштерелгән төркемнәре буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларга билгеләнә. Кабул итүнең контроль саннары шулай ук, әгәр белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан Федераль законның 100 статьясында билгеләнгән таләпләр үтәлеп, урта һөнәри һәм югары белемнең уку-укыту программаларына дәүләт аккредитациясе әлегрәк үткәрелмәгән булса, урта һөнәри һәм югары белемнең дәүләт аккредитациясе булмаган уку-укыту программалары нигезендә белем бирү өчен һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре һәм

(яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең, әзерлек юнәлешләренең гомумиләштерелгән төркемнәре буенча билгеләнергә мөмкин.».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 16 марты
№ 14-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 205. «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш), № 12 (X өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2012, № 1, № 9; 2014, № 6 (II өлеш), № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә «шушы гражданнарның яшәү урыны буенча бирелгән гаризалары нигезендә вәкаләтле орган» сүзләрен «вәкаләтле орган шушы гражданнарның күрсәтелгән



органга алар тарафыннан яшәү урыны буенча бирелгән яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәге аша юлланган гаризалары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяда:

а) икенче абзацта «социаль наем шартнамәләре» сүзләреннән соң «, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре» сүзләрен өстәргә, «социаль наем шартнамәсе» сүзләреннән соң «, социаль файдаланудагы торак фондының торак урынына наем шартнамәсе» сүзләрен өстәргә;

б) өченче абзацта «социаль наем шартнамәләре» сүзләреннән соң «, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре» сүзләрен өстәргә, «социаль наем шартнамәсе» сүзләреннән соң «, социаль файдаланудагы торак фондының торак урынына наем шартнамәсе» сүзләрен өстәргә;

в) бишенче абзацта «социаль наем шартнамәләре» сүзләреннән соң «, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре» сүзләрен өстәргә, ике урында «социаль наем шартнамәсе» сүзләреннән соң «, социаль файдаланудагы торак фондының торак урынына наем шартнамәсе» сүзләрен өстәргә;

3) 15 статьяның 2 өлешендәге дүртенче абзацында «гараж-төзелеш һәм дача-төзелеш» сүзләрен «гараж һәм дача кулланучылар» сүзләренә алмаштырырга;

4) 18 статьяда:

а) 1 өлештә «тиешле күчемсез мөлкәт объектларын техник исәпкә алуны һәм инвентарьлаштыруны үткәрүгә аккредитацияләнгән оешмалардан» сүзләрен «күчемсез мөлкәтне кадастр исәбенә алуны һәм аның дәүләт кадастрын алып баруны гамәлгә ашыра торган органнан тиешле» сүзләренә алмаштырырга, «инвентарьлаштырылган» сүзен «кадастр» сүзенә алмаштырырга, «инвентарьлаштыру» сүзен «кадастр» сүзенә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «, ә аны билгеләгәнчегә кадәр, җир турындагы законнарга таянып, җирнең норматив бәясе нигезендә билгеләнә» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 20 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Торак-төзелеш, гараж һәм дача кулланучылар кооперативларында пай җыелмалары хакын билгеләү мөрәҗәгать итүче граждан тарафыннан бирелгән һәм торак-төзелеш, гараж һәм

дача кулланучылар кооперативлары тарафыннан таныкланган белешмәләр нигезендә башкарыла.»;

6) 25 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак вәкаләтле орган тарафыннан яшәү урыны буенча исәпкә куелган һәм социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча башка муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан торак урыннары бирелүгә бәйле рәвештә яшәү урынын үзгәрткән гражданнар торак урыннарына мохтаҗлар буларак аларның элекке яшәү урыны буенча исәптән төшерелергә тиеш түгел.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 16 марты
№ 15-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 206. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законның $16^{6}$ һәм $16^{6\text{-}1}$ статьяларын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законның $16^{6}$ һәм $16^{6\text{-}1}$ статьяларын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2012 елның 28 декабрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Татарстан Республикасында гражданнарның эконом классы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында»;**

2) 1 статьяда «Федераль законның (алга таба – Федераль закон) $16^{6}$ статьясындагы 36 өлеше, $16^{6\text{-}1}$ статьясындагы 20 өлеше» сүзләрен «Федераль закон (алга таба – Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга, «, шулай ук «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарның эконом класслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга сала»;

3) 2 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарның эконом класслы торак сатып алу хокукына ия категорияләре исемлеген раслый, җирле үзидарә органнары тарафыннан мөрәҗәгать итүче гражданнарның эконом классы торак сатып алу хокукына ия гражданнарның билгеләнгән категорияләренә туры килүен тикшерү тәртибен, җирле үзидарә органнары тарафыннан эконом классы торак сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен төзү һәм раслау тәртибен, аларга үзгәрешләр кертү тәртибен, шулай ук мондый исемлеккә кертелгән гражданнарның Татарстан Республикасы буенча җыелма реестрын алып бару тәртибен һәм күрсәтелгән реестрда булган белешмәләрне Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә эконом классы торак төзү максатларында территорияләрне үзләштерү турында шартнамәләр яисә эконом классы торак төзү максатларында территорияләрне комплекслы үзләштерү турында шартнамәләр төзегән юридик затларга бирү тәртибен билгели.»;

б) 2 өлештә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Федераль законның 11 статьясындагы $6^{8}$ һәм $6^{9}$ өлешләре нигезендә, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тәкъдимнәренә таянып, эконом классы торак төзелешенә ихтыяҗ булу турын-

да үтенечнамә (алга таба – үтенечнамә) әзерли һәм Фонд тарафыннан алга таба Федераль законның $16^{6}$ – $16^{6-2}$ статьяларында каралган аукционнар үткәрү максатларында Фондка җибәрә;»;

3 пунктта «җир кишәрлекләре» сүзләреннән соң «, дәүләт милке итеп алынмаган җир кишәрлекләре» сүзләрен өстәргә;

5 пунктта «җир кишәрлекләрен» сүзләреннән соң «, дәүләт милке итеп алынмаган җир кишәрлекләрен» сүзләрен өстәргә, «$16^{6}$, $16^{6-1}$ статьялары» сүзләрен «$16^{6}$ – $16^{6-2}$ статьялары» сүзләренә алмаштырырга;

4) 3 статьяның 2 өлешендәге 3 пунктының «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан, эконом класслы торак төзү өчен аукционнар үткәрелергә мөмкин федераль милектәге яисә дәүләт милке итеп алынмаган җир кишәрлекләре турында;»;

5) 6 статьяның 9 өлешендә «Федераль законның $16^{16-1}$ статьясындагы 30 өлешенең 2 пунктында» сүзләрен «Федераль законның $16^{16-1}$ статьясындагы 30 өлешенең 2 пунктында һәм $16^{16-2}$ статьясындагы 31 өлешенең 2 пунктында» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 16 марты
№ 16-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 207. «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2005, № 7 – 8; 2008, № 5 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 7 пунктында «барлык милек рәвешләрендәге оешмалар» сүзләреннән соң «(алга таба – барлык милек рәвешләрендәге оешмалар)» сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле $8^{1}$ статья өстәргә:

«$8^{1}$ статья. **Барлык милек рәвешләрендәге оешмаларның махсуслаштырылган оешмалар белән хезмәттәшлеге**

Барлык милек рәвешләрендәге оешмалар үзләре кабул иткән карарлар нигезендә торак шартларын социаль ипотека системасында яхшыртуга мохтаҗ хезмәткәрләренең гаиләләрен исәпкә ала һәм аларның реестрын алып бара, реестрны махсуслаштырылган оешмаларга бирә.»;

3) 9 статьяда:

а) 1 пунктта «торак төзелеше үсешен финанслауда катнашучы» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 11 пунктта «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «, барлык милек рәвешләрендәге оешмалар» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 28 марты
№ 17-ТРЗ



# II ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҺӘМ АНЫҢ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 208. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының алтынчы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы алтынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Кеше күп була торган объектларда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм федераль законнарга үзгәрешләр кертү турында.
2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2014 елгы эшчәнлеге турында хисап.
3. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
4. Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча 10 нчы суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
5. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 41-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (III укылыш).
6. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 45-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).
7. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының $1.1^1$ һәм 8.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 83-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үз-

гәрешләр кертү хакында» 81-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» 86-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 87-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 88-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 89-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 82-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Вөҗдан ирегә турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» 80-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Яшь ярымнан алып өч яшькә кадәрге балалар тәрбияләүче аерым категорияләрдәге гражданнарга айлык акчалата түләү бирү турында» 74-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

16. «2014 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен үтәү турында» Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады.

17. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты составындагы үзгәреш турында.

18. «Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссияләрен төзү турында» 2014 елның 26 ноябрендәге



217-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәреш кертү хакында.

19. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына Россия Федерациясе субъектларына административ штрафлар күләмнәрен билгеләү өлешендә хокукый җайга салу вәкаләтләрен бирү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 697378-6 номерлы федераль закон проекты турында.

20. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 һәм 30.7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 703836-6 номерлы федераль закон проекты турында.

21. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 17.7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 699531-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозу турындагы эшне алып баручы прокурорның, тикшерүченең, сорау алучының яисә вазыйфаи затның законлы таләпләрен үтәмәгән өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында).

22. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 688452-6 номерлы федераль закон проекты турында (эчке эшләр органнары вазыйфаи затларының вәкаләтләрен төгәлләштерү өлешендә).

23. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына эшкуарлык эшчәнлеген юридик зат төземичә гамәлгә ашыручы затларның автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм йөкләр ташу хезмәтләрен күрсәткәндә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү таләпләрен бозган өчен административ җаваплылыгын көчәйтү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 721264-6 номерлы федераль закон проекты турында.

24. «Үтәтү эшләрен башкару турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 711269-6 номерлы федераль закон проекты турында (үтәтү эшләрен башкару хакындагы законнарда түләтүченең үз мөлкәте белән эш йөртү буенча бурычлының алыш-бирешләренә дәгъва белдерү хокукын беркетү).

25. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына һәм «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында» Федераль законның 59 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 709323-6 номерлы федераль закон проекты турында (чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга карата өстәмә административ җәзалау буларак аларны Россия Федерациясеннән административ куып чыгаруны альтернативасыз куллануны бетерү максатларында).

26. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясына үзгәреш кертү хакын-

да» 719981-6 номерлы федераль закон проекты турында (Дәүләт янгын куркынычсызлыгы хезмәтенең федераль янгын куркынычсызлыгы хезмәте бүлекчәләре җитәкчеләренә Кодексның 20.4 статьясы буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү хокукын бирү өлешендә).

27. «Юл хәрәкәте иминлеге турында» Федераль законның 24 статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына тәүлекнең караңгы вакытында яисә күз күреме начар булу шартларында гражданнарның юл хәрәкәтендә имин катнашуларын тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

28. «Чернобыль АЭС һәлакәте аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль ярдәм турында» РСФСР Законының гамәлдә булуын аеруча куркыныч янаган төркемнәрдәге гражданнарга тарату хакында» Россия Федерациясе Югары Советы карарының 2 пунктына үзгәреш кертү турында» 714104-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе Конституция Судының 2014 елның 1 июлендәге 20-П номерлы карарын башкару турында).

29. «Россия Федерациясе Гаилә кодексының 100 статьясына үзгәреш кертү турында» 688424-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе Граждан кодексының гамәлдәге редакциясенә тәңгәлләштерү турында).

30. «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 722937-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе спорт җыелма командалары өчен чыгыш ясарга хокукы булмаган спортсменнарның спортның команда төрләре буенча халыкара спорт ярышларында һәм (яисә) бөтенроссия спорт ярышларында катнашу үзенчәлекләрен җайга салу өлешендә).

31. «Биомедицина күзәнәк продуктлары турында» 717040-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

32. «Россия Федерациясе Торак кодексының 170 һәм 179 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 691959-6 номерлы федераль закон проекты хакында (региональ оператор счетын булдырганда капиталь ремонт фонды күләмен арттыру өлешендә).

33. «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Россия Федерациясе Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 712965-6 номерлы федераль закон проекты турында (азык-төлек



продуктларында ГМО-компонентларның барлыгы турындагы мәгълүмат өлешендә).

34. «Россия Фәннәр академиясе, дәүләт фәннәр академияләрен үзгәртеп оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон кабул итүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 713531-6 номерлы федераль закон проекты турында.

35. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына аларны «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга тәңгәлләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 711831-6 номерлы федераль закон проекты турында.

36. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чечен Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы турында.

37. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12[1] статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

38. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына салым базасын һәм бюджеттан тыш дәүләт фондларына салым кертемнәрен исәпләү базасын күрсәтми калган өчен эш бирүчеләрнең җаваплылыгын көчәйтү максатларында үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Хакасия Республикасы Югары Советының закон чыгару инициативасы хакында.

39. «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-исәп органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законның 16 статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 697663-6 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт финанс контроле, муниципаль финанс контроле органының (вазыйфаи затының) законлы таләпләрен (сорауларын), шулай ук күрсәтмәләрен үтәмәгән өчен җаваплылыкка тарту механизмын төгәлләштерү өлешендә).

40. «Россия Федерациясе Салым кодексының 149 статьясына үзгәреш кертү турында» 708617-6 номерлы федераль закон проекты хакында (өстәлгән бәяләргә салымга салым салудан азат ителә торган товарлар исемлегеннән инвалидлыкны профилактикалауда кулланыла торган техник чараларны һәм материалларны төшереп калдыру өлешендә).

41. «Россия Федерациясе Салым кодексына «Иминият пенсияләре турында» һәм «Тупланма пенсия турында» федераль законнар кабул итүгә бәйле рәвештә үзгәрешләр кертү хакында» 708771-6 номерлы федераль закон проекты турында (физик затлар керемнәре, чыгымнары төрләрен, дәүләт пошлиналары, салымны кире кайтару төрләрен төгәлләштерү өлешендә).

42. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 93.2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 712943-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр өчен бюджет кредитыннан файдалануга максималь ставка билгеләү өлешендә).

43. «Россия Федерациясе Салым кодексының V[1] бүлегенә үзгәрешләр кертү турында» 714002-6 номерлы федераль закон проекты хакында (салым түләүчеләр тарафыннан салым базасына һәм тиешле салымнар (зыяннар) суммаларына симметрияле корректировкалар кертү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).

44. «Россия Федерациясенә Кырым Республикасын кабул итүгә һәм Россия Федерациясе составында яңа субъектлар — Кырым Республикасын һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәрен төзүгә бәйле рәвештә җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуның үзенчәлекләре турында» 714167-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

45. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына геннар инженериясе эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт җайга салуын камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 714809-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

46. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен стратегик әһәмияткә ия хуҗалык җәмгыятьләренә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында» Федераль закон кабул итүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» Федераль законның 12 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 722959-6 номерлы федераль закон проекты турында (федераль әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын бирү үзенчәлекләре хакында).



47. «Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чечен Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы турында.

48. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Краснодар крае Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

49. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 464-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 209. Кеше күп була торган объектларда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм федераль законнарга үзгәрешләр кертү турында

«Яңа Тура» технополисындагы, «Витарус» сәүдә комплексындагы (Вьетнам базары) янгыннар турында, шулай ук кешеләрнең үлеменә китергән, кеше күп була торган объектларда оештыру-хокукый характердагы җитди җитешсезлекләр барлыгы һәм янгын куркынычсызлыгы чараларын көчәйтү таләп ителә торган проблемалар барлыгы ачыкланган «Адмирал» сәүдә комплексындагы фаҗигале вакыйгалар хакында Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары А.В. Песошин докладын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына ике атна эчендә «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге

294-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына, кирәк булган очракта, башка закон актларына үзгәрешләр кертү хакында федераль закон проектлары әзерләүне һәм закон чыгару инициативасы тәртибендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертүне йөкләргә.

2. Кеше күп була торган объектларда янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәүне оештыру һәм гамәлгә ашыру, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча үзләренә йөкләнгән бурычларны тиешенчә үтәмәү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты координация эшенең җитәрлек булмавын, Татарстан Республикасы буенча федераль контроль-күзәтчелек органнарының, республика контроль-күзәтчелек органнарының, җирле үзидарә органнарының системалы эшенең җитәрлек булмавын билгеләп үтәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы буенча федераль контроль-күзәтчелек органнары, республика контроль-күзәтчелек органнары, җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов йөкләмәсен үтәү йомгаклары буенча 2015 елның 1 июленә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә объектлар буенча янгынга каршы чараларның комплекслы планын эшләргә һәм расларга тиеш.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан тәкъдим ителгән федераль закон проектларын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чираттагы утырышында карауга әзерләргә тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынова йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 465-V ДС



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 210. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2014 елгы эшчәнлеге турында хисап хакында

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2014 елгы эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Президенты тәкъдим иткән хисапны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2014 елгы эшчәнлеге турында хисапны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2014 елгы эшчәнлеге турында хисап буенча фикер алышу барышында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының депутат берләшмәләреннән, депутатларыннан алынган тәкъдимнәрне карау һәм чаралар күрү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2014 елгы эшчәнлеге турындагы хисапны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Интернет» мәгълүматкоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми сайтында урнаштыруны тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 466-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 211. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп биш елга Татарстан Республикасы Түбән Кама суд районы буенча:

5 нче суд участогына – Мифтахов Марат Мансур улын сайларга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 467-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 212. Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча 10 нчы суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законының 7[1] статьясы һәм «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча 10 нчы суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруны бер елга отставкадагы судья Такаева Наталия Григорьевнага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 468-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 213. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (41-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (41-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 469-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 214. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законы хакында (45-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законын (45-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 470-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 215. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының $1.1^1$ һәм 8.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 83-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының $1.1^1$ һәм 8.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 83-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 471-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 216. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының $1.1^1$ һәм 8.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (83-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының $1.1^1$ һәм 8.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (83-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 472-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 217. «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 81-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 81-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 473-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 218. «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (81-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (81-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 474-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 219. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» 86-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» 86-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 475-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 220. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (86-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (86-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 476-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 221. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 87-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 87-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 477-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 222. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (87-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (87-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 478-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**223. «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 88-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Т. Борһанов тарафыннан кертелгән «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 88-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 479-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**224. «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (88-5 номерлы проект)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (88-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 480-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**225. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 89-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Т. Борһанов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законы-

на үзгәрешләр кертү хакында» 89-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2015 елның 4 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2015 елның 1 маена кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 481-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 226. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 82-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 82-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 482-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 227. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (82-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (82-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 483-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 228. «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» 80-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты тарафыннан кертелгән «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» 80-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 484-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 229. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (80-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (80-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 485-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 230. «Яшь ярымнан алып өч яшькә кадәрге балалар тәрбияләүче аерым категорияләрдәге гражданнарга айлык акчалата түләү бирү турында» 74-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Х.Г. Миргалимов, А.В. Комисаров, А.В. Прокофьев тарафыннан кертелгән «Яшь ярымнан алып өч яшькә кадәрге балалар тәрбияләүче аерым категорияләрдәге гражданнарга айлык акчалата түләү бирү турында» 74-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын кире кагарга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 486-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 231. «2014 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен үтәү турында» Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады хакында

«2014 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен үтәү турында» Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил докладын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «2014 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен үтәү турында» Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л. Удачинаның докладын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы министрлыкларына һәм ведомстволарына, муниципаль берәмлекләр башлыкларына «2014 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен үтәү турында» Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил докладындагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чараларын, шулай ук бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен үтәү буенча гамәлләр комплексын эшләү чараларын күрүне тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 487-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 232. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты составындагы үзгәреш турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Гыймадиев Илдар Шамил улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты әгъзасы итеп сайларга.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетын сайлау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның 1 октябрендәге 16-V ДС номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

икенче абзацта «14» санын «15» санына алмаштырырга;

өченче абзацта «Ганиев Илшат Газим улы» сүзләреннән соң «Гыймадиев Илдар Шамил улы» сүзләрен өстәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 488-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 233. «Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссияләрен төзү турында» 2014 елның 26 ноябрендәге 217-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссияләрен төзү турында» 2014 елның 26 ноябрендәге 217-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән төзелгән «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Комиссиясе составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты әгъзасы Гыймадиев Илдар Шамил улын кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 489-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 234. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына Россия Федерациясе субъектларына административ штрафлар күләмнәрен билгеләү өлешендә хокукый җайга салу вәкаләтләрен бирү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 697378-6 номерлы федераль закон проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына Россия Федерациясе субъектларына административ штрафлар күләмнәрен билгеләү өлешендә хокукый җайга салу вәкаләтләрен бирү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 697378-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 490-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 235. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 һәм 30.7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 703836-6 номерлы федераль закон проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 һәм 30.7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 703836-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 марты
№ 491-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

